**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 июль № 508

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 23 гыйнвар, 34 нче, 2015 ел, 13 март, 151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктта:

беренче абзацта «бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча компенсация түләүгә гариза» сүзләренә кадәр «җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (эш бирүчегә Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган» сүзләрен өстәргә;

беренче пунктчада «бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар реестрын» сүзләренә кадәр «җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (эш бирүчегә Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган» сүзләрен өстәргә;

дүртенче пунктчада «бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән тәэмин итүче хезмәтләр күрсәткән өчен компенсация түләүгә белешмә-исәп-хисап» сүзләренә кадәр «җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (эш бирүчегә Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) расланган» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «мөһер белән» сүзләреннән соң «(эш бирүчегә Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацтагы «27 июнь» сүзләрен «27 июль» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\508.doc